# КАРАР

2021 елның 18 ноябре, № 1

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Ямбулат-Пустошь авылында узара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 18 ноябрендә үткән гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә түбәндәге сорау буенча:

Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Ямбулат-Пустошь авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны:
- Ямбулат-Пустошь авылына вак таш түшәү, юлны карап тоту һәм ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру; Ямбулат-Пустошь авылы юлларын кардан чистарту (түләү килешү буенча) эшләрен башкаруга юнәлтүгә ризамы ?:
« РИЗА» "КАРШЫ"

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 12 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 7 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» дип гражданнар җыенында катнашучы 7 кеше тавыш бирде;
«юк» дип гражданнар җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.
Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Ямбулат-Пустошь авылында узган гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре – кабул ителгән дип танырга.

Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Ямбулат-Пустошь авылы территориясендә теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны:

- Ямбулат-Пустошь авылына вак таш түшәү, юлны карап тоту һәм ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру; Ямбулат-Пустош авылы юлларын кардан чистарту (түләү килешү буенча) эшләрен башкаруга юнәлтүгә ризамы ?:

«РИЗА» -кабул ителгән. «КАРШЫ»

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Ятмас- Дусай
авыл җирлеге башлыгы Ф. Х. Гарифуллина